| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**19.02.2026** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 579** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 11 июлендәге 1892 номерлы карары белән расланган, гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2025 елның 09 сентябрендәге 2439 номерлы караындагы үзгәрешләр белән)

Россия Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау һәм күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантларны алучыларны сайлап алуны уздыру турында» 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларыннан субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 20 мартындагы 210 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 11 июлендәге 1892 номерлы карары белән расланган, гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне (2025 елның 09 сентябрендәге 2439 номерлы караындагы үзгәрешләр белән) кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.6 пунктындагы 8 пунктчасын, 19 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 4.7 пунктның унберенче абзацын төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru ) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2026 елның 01 гыйнварыннан хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин